Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре
2017-2018 уку елы
4 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 60 минут.

Максималь балл – 36.

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Татар алфавитындагы хәрефләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) 36

ә) 38

б) 39

в) 40

2. Парсыз яңгырау тартыклар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) [м], [н], [ң], [л], [й], [р], [w]

ә) [ц], [щ], [х], [h], [ʼ]

б) [м], [л], [б], [р]

в) [б], [в], [г], [гъ], [д], [ж], [з], [ж]

3. Калын сузыклардан торган сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) икмәк, кишер, Гөлчәчәк

ә) алъяпкыч, тукыма, коймак

б) бишбармак, тукран, төлке

в) елан, егет, чыршы

4. Хәреф белән аваз саны туры килмәгән сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) карбыз, кавын, тарак

ә) төньяк, өчпочмак, каләм

б) белем, көньяк, аю

в) юрган, елга, яфрак

5. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең килешен билгеләгез. ***(2 балл)***

Сүздә *мактанма,* ***эштә*** *мактан.* (Мәкаль)

а) иялек килеше

ә) юнәлеш килеше

б) чыгыш килеше

в) урын-вакыт килеше

6. Җыйнак җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Сафина Ләйсән – тырыш укучы.

ә) Сары яфраклар җир өстен каплаган.

б) Мансурова Лилия, Айдаров Марат – укучылар.

в) Тәрәзәләргә пәрдә эленгән.

7. Үткән заман хикәя фигыль кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Урамда көчле яңгыр ява.

ә) Бүген Азат әбисенә кунакка барды.

б) Спорт сараенда хоккей ярышы булачак.

в) Тиздән кошлар җылы якларга китәр.

8. Ялгызлык исемнәрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) болыт, үлән, агач

ә) гөлчәчәк, йолдыз, аккош

б) Айсылу, Идел, “Салават күпере”

в) ай, кояш, “Су анасы”

II. Теоретик бирем.

Хәзерге заман хикәя фигыль турында языгыз, бер фигыльне затсан белән төрләндерегез. ***(10 балл)***

III. Иҗади бирем.

Уңнан да, сулдан да бертөрле укыла торган 10 сүз языгыз. ***(10 балл)***